**СОВЕТ**
**НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
улица Советская, д.10, с.Новый Кинер,
Арский муниципальный район, 422031

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЯҢА КЕНӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 10 нче йорт, Яңа Кенәр авылы, Арча муниципаль районы, 422031

Тел.,факс (84366)9-12-65, (84366)9-12-68, 9-12-60. E-mail: Nkin.Ars@tatar.ru

**Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**«18» апрель 2016 ел** **№ 24**

**Яңа Кенәр авыл җирлеге Советының 01.11.2014 № 105 карары белән расланган Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы аппаратында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы аппаратында һәм авыл җирлеге башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 03 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Яңа Кенәр авыл җирлеге Советының 01.11.2014 № 105 карары белән расланган Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы аппаратында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы аппаратында һәм авыл җирлеге башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

в)үз чыгымнары, шулай ук җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлары) сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүматлар тапшыру елыннан алдагы календарь ел дәвамында - әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге өч ел эчендә әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә һәм әлеге алыш-бирешләр кылган акчалар алу чыганаклары турында.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы Фәхретдинов Р.Ә.